**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

31.08.2018г. № 341

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 декабрендәге 516 номерлы “Әлки муниципаль районы чикләре буйлап торак пунктлар арасында гомуми файдаланудагы җир өслегендә автомобиль транспортында пассажирларны һәм багаж ташу Кагыйдәләрен раслау” карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44 – ФЗ номерлы Федераль законга, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 декабрендәге 516 номерлы карары белән расланган “Әлки муниципаль районы чикләре буйлап торак пунктлар арасында гомуми файдаланудагы җир өслегендә автомобиль транспортында пассажирларны һәм багаж ташу Кагыйдәләрен раслау” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3нче бүлекнең 6 нчы абзацында «заказ» сүзен «сатып алу " сүзләренә алмаштырырга»;
- 4 бүлекнең 5 абзацында «муниципаль заказ» сүзләрен «дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр, хезмәтләр күрсәтү " сүзләренә алмаштырырга»;
- 10 бүлекнең 4 абзацында «муниципаль заказ» сүзләрен «дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр, хезмәтләр күрсәтү»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Балакирев С.Н. йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе — Йосыпов И.В.